**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28.07.2023 ел** **№ 998**

## Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга акча рәвешендә матди ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 ноябрендәге 879 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-фз номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә һәм ялгыз яшәүче гражданнарга матди ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә күрсәтү турында» 2014 елның 02 сентябрендәге 635 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга акча рәвешендә матди ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 ноябрендәге 879 номерлы карары белән расланган авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга акча рәвешендә матди ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Матди ярдәм күләме 50 000 сумнан арта алмый.»

1.2. 6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча белән тулыландырырга:

«7) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләре (гаилә әгъзалары);»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин